ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

26.05.2020г. № 14

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон нигезендә Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravotatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Арча муниципаль районы
Урта Курса авыл җирлеге
Башкарма комитетының
«26» май 2020 ел, № 14 карарына
1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Арча муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслауга карата гомуми таләпләрне билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

административ регламент - муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын билгели торган норматив хокукый акт;

муниципаль хезмәт күрсәтү- җирле үзидарә органының (алга таба - муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган) мөрәҗәгать итүчеләр соравы буенча "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм муниципаль берәмлекләр уставлары нигезендә, шулай ук күрсәтелгән Федераль Законда җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә хокукларын, җирле үзидарә органнарының (күрсәтелгән Федераль законның 19 статьясы нигезендә тапшырылмаган) башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу хокукларын бу катнашу федераль законнарда җирле үзидарә органнарының башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кермәгән һәм федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән үз вәкаләтләреннән чыгарылмаган бүтән мәсьәләләрне хәл итү хокукларында каралган мондый хокукларны гамәлгә ашыру турында муниципаль хокукый актлар кабул ителгән очракта, федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән каралган функцияләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеге;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - күпфункцияле үзәк) - федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне, шул исәптән электрон формада, “бер тәрәзә" принцибы буенча оештыру-хокукый формада дәүләт яки муниципаль учреждениенең (шул исәптән автоном учреждение) оештыру-хокукый формасында булдырылган оешма;

муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба - шикаять) - мөрәҗәгать итүченең яисә аның законлы вәкиленең җирле үзидарә органы, күпфункцияле үзәк, җирле үзидарә органының вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, муниципаль хезмәткәр яисә Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелгән муниципаль хезмәтне алганда мөрәҗәгать итүченең бозылган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау турында таләбе;

"бер тәрәзә" принцибы- мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында бер тапкыр мөрәҗәгать итүе яисә Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуы нәтиҗәсендә муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук норматив хокукый актлар һәм үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән үзара хезмәттәшлек итү күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүченең катнашыннан башка гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны - Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру

Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис).

1.3. Административ регламентлар җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнары турындагы нигезләмәләр һәм әлеге Тәртип нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибенә карата административ процедураларның, административ гамәлләрнең һәм (яисә) карарлар кабул итүнең критерийларын, срокларын һәм эзлеклелеген билгеләгән хөкүмәт координация органнары карарларын һәм муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибенә карата башка таләпләрне исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыру вәкаләтләре барлыкка килгән көннән 60 календарь көн эчендә эшләнә һәм раслана.

1.4. Административ регламентларны эшләгәндә һәм раслаганда җирле үзидарә органы әлеге Тәртипкә таяна, әгәр федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары белән башка кагыйдәләр билгеләнмәгән булса.

1.5. Җирле үзидарә органнарының административ регламентларын эшләгәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оптимальләштерү (сыйфатын күтәрү) буенча түбәндәгеләрне күздә тота:

а) административ процедураларны (гамәлләрне) тәртипкә салу;

б) федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларына, муниципаль хокукый актларга каршы килмәсә, артык административ процедураларны (гамәлләр) бетерү.

Артык административ процедура дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын начарайтуга китермәгән административ процессның бер өлешен төшереп калдыру (мәсәлән, артык килештерүләр (килештерү нәтиҗәсе карарга йогынты ясамаганда), артык хәбәрнамәләр һ.б.) аңлашыла.

Артык административ гамәл дигәндә административ гамәлне административ процедурадан төшереп калдыру өстәмә чыгымнарсыз гына административ процедура нәтиҗәсенә ирешергә мөмкинлек бирә торган административ гамәлләр аңлашыла;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документлар санын кыскарту, берничә тапкыр шундый мәгълүмат бирү зарурлыгын юкка чыгарырга мөмкинлек бирә торган документларның яңа формаларын куллану, күпфункцияле үзәкләр базасында аерым административ процедураларны (гамәлләр) үтәү һәм «бер тәрәзә» принцибын гамәлгә ашыру исәбенә мөрәҗәгать итүченең катнашыннан башка, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләре кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтүдә ведомствоара килешүләрдән файдалану;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында аерым административ процедураларны (гамәлләрне) башкару срокларын кыскарту. Җирле үзидарә органы административ регламентта муниципаль хезмәт күрсәтүнең кыскартылган срокларын, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тиешле срокларга карата муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында административ процедураларны (гамәлләр) үтәү срокларын билгеләргә мөмкин;

д) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының административ процедураларны (гамәлләрне) үтәгәндә административ регламентлар таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылыгы;

е) муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү.

1.6. Административ регламентны эшләгәндә җирле үзидарә органы структураны һәм административ процедуралар (гамәлләр) тәртибен әзерләү өчен административ-идарә процессларын тасвирлауның һәм модельләштерүнең электрон чараларын куллана ала.

1.7. Җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ

регламентларында җирле үзидарә органнарының федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары нигезендә аларның компетенцияләренә кертелмәгән вәкаләтләрен билгеләргә хокуклы түгел.

1.8. Административ регламентлар проектлары, шулай ук элек чыгарылган административ регламентларга үзгәрешләр кертү, административ регламентларның үз көчләрен югалтуын тану турындагы норматив хокукый актлар проектлары законнар нигезендә бәйсез экспертиза һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләүне методик яктан тәэмин итүгә һәм аларга экспертиза үткәрүгә вәкаләтле оешма (алга таба - вәкаләтле оешма) тарафыннан үткәрелергә тиеш.

Административ регламентлар проектларына, шулай ук элек чыгарылган административ регламентларга үзгәрешләр кертү, административ регламентларны үз көчләрен югалткан дип тану турындагы норматив хокукый актлар проектларына экспертиза әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

1.9. Әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтүдә берничә җирле үзидарә органы катнашса, административ регламент мондый органнарның уртак акты белән раслана.

Җирле үзидарә органнары арасында административ регламентлар проектлары буенча каршылыклар җирле үзидарә органы Регламентында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

1.10. Җирле үзидарә органы административ регламентны раслау белән бер үк вакытта муниципаль хезмәт күрсәтүне регламентлый торган нигезләмәләрне төшереп калдыруны күздә тоткан тиешле муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертә, яисә муниципаль норматив хокукый актларның нигезләмәләре административ регламентка кертелгән булса, аларның үз көчләрен югалтуларын таный.

Административ регламент проекты, элек чыгарылган административ регламентка үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проектын эшләү барышында тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен җайга салучы башка норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертү шарты белән тиешле муниципаль хезмәт күрсәтүне оптимальләштерү (сыйфатын күтәрү) мөмкинчелеге туса, административ регламент проекты яисә элек чыгарылган административ регламентка үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проекты, тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар проектларын кушып, вәкаләтле оешмага экспертизага җибәрелә.

1.11. Административ регламентлар билгеләнгән тәртиптә расланганнан соң 10 эш көне эчендә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасын алып бару буенча вәкаләтле органга җибәрелергә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә административ регламентны раслаган җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

1.12. Административ регламентларга үзгәрешләр кертү муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары үзгәргән очракта, тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү керә торган җирле үзидарә органнары структурасындагы үзгәрешләр, күрсәтелгән административ регламентларны куллану мониторингы нәтиҗәләре буенча законнарда каралган башка очракларда гамәлгә ашырыла.

Административ регламентларга үзгәрешләр кертү тиешле административ регламентларны эшләү, килештерү һәм раслау өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

1.13. Административ регламентлар дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматны һәркем ала алырлык булу турында Россия Федерациясе законнары нигезендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларның рәсми сайтларында бастырып чыгарылырга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарында килүчеләр күрә алырлык урыннарда урнаштырылырга тиеш.

## II. Административ регламентларга карата таләпләр

2.1. Административ регламентның исеме, тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү каралган норматив хокукый акт нигезләмәләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтүдә берничә җирле үзидарә органы катнашса, административ регламентның исеме әлеге органнарның уртак боерыгы белән билгеләнә.

2.2. Административ регламентка түбәндәге бүлекләр кертелә:

а) гомуми нигезләмәләр;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты;

в) административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары;

д) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе;

е) күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре. Әгәр муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелмәсә, әлеге бүлек административ регламентларга кертелми.

2.3. Гомуми нигезләмәләргә кагылышлы бүлек түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

1) административ регламентны җайга салу предметы;

2) мөрәҗәгать итүчеләрнең ташламалы категорияләрен күрсәтеп (булган очракта), мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгать итүче юридик һәм физик затлар исемлеге китерелә торган категорияләре (затлар категориясе);

3) муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән:

муниципаль хезмәт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча гариза бирүчеләр тарафыннан мәгълүмат алу тәртибе, әлеге хезмәтләрне күрсәтү барышы турында, шул исәптән җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, шулай ук «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, мәгълүмат алу тәртибе.

б) әлеге пунктчада күрсәтелгән мәгълүматны алу тәртибе, формасы, урнашу урыны һәм аны алу ысуллары, шул исәптән муниципаль хезмәт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү урыннарындагы стендлар, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук җирле үзидарә органнарының рәсми порталы, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларның рәсми сайтлары, шулай ук «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасы аша;

в) мәгълүматны муниципаль хезмәтләр күрсәтү урыннарында стендларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәҗбүри урнаштыру буенча таләпләр:

җирле үзидарә органы тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт атамасы;

муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау;

муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатылу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге (шул исәптән әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать, документлар тапшыруның ирекле формасы каралган очраклардан тыш, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган

хезмәтләрдән тыш), аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе һәм шартлары;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;

муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен өчен алына торган дәүләт пошлинасы яисә башка түләү күләме;

җирле үзидарә органнарының эш вакыты, җирле үзидарә органнары белгечләре тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүмат;

мөрәҗәгать итүчеләр өчен аларның муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кылынган гамәлләргә (кылынмаган гамәлләргә) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукы турында мәгълүмат.

Белешмә мәгълүматка түбәндәге мәгълүмат керә:

җирле үзидарә органының, аның структур бүлекчәләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче территориаль органнарның, дәүләт һәм муниципаль органнарның һәм оешмаларның, шулай ук күп функцияле үзәкнең читтәге эш урыннарының урнашу урыннары һәм эш графиклары;

җирле үзидарә органнары структур бүлекчәләренең, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларның белешмә телефоннары, шул исәптән автоинформатор-телефон номеры;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайты, шулай ук электрон почта адресы һәм (яки) кире элемтә формасы.

Белешмә мәгълүмат җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында мәҗбүри урнаштырылырга тиеш. Җирле үзидарә органнары «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасының тиешле бүлегендә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми сайтта белешмә мәгълүмат урнаштыруны һәм актуальләштерүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәләр;

4) норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүне турыдан-туры җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

5) административ регламентта кулланыла торган терминнар һәм аларның билгеләмәсе.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең атамасы», «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге», «Күрсәтелә торган хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графалары булган таблица рәвешендә рәсмиләштерелә һәм түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

а) муниципаль хезмәтнең аталышы;

б) җирле үзидарә органы исеме.

Әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтүдә башка җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар катнаша икән, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган барлык органнар һәм оешмалар күрсәтелә. Шулай ук Федераль законның 7 статьясындагы 3 пункты таләпләре, аерым алганда, мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка органнарга һәм оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлегенә кертелгән хезмәтләрдән тыш, килештерүләрне гамәлгә ашыруны, шул исәптән, тыюны билгеләү дә күрсәтелә;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, әгәр Россия Федерациясе законнарында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору каралган булса, туктатып торуның срогы,

муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе (бланклар, мөрәҗәгать, гариза формалары һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә бирелә торган башка документлар административ регламентның кушымтасы буларак китереләләр (әлеге документларның формалары Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Президенты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очраклардан тыш, шулай ук закон тарафыннан бу документларны ирекле рәвештә тапшыру каралган очраклардан тыш).

Җирле үзидарә органнары тарафыннан административ регламентларга кертүгә тәкъдим ителә торган мөрәҗәгатьнең типлаштырылган формасы күрсәтелгән документлар формалары Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм муниципаль норматив актлар белән билгеләнгән очраклардан тыш, шулай ук законнарда әлеге документларны тапшыруның ирекле рәвеше каралган очраклардан тыш, әлеге Тәртипнең кушымтасында китерелгән;

е) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы (бланклар, мөрәҗәгать, гариза формалары һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә бирелә торган башка документлар административ регламентның кушымтасы буларак китереләләр, Россия Федерациясе законнары белән әлеге документларны бирүнең ирекле формасы каралган очраклардан тыш).

Мөрәҗәгать итүченең күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Бу бүлекчәдә шулай ук мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар белән тапшыру яки башкару каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны таләп итү;

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органнары һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат таләп итү, Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә, Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, башка очракларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны таләп итү;

ж) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;

з) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге. Нигезләр булмаганда, ул административ регламент текстында күрсәтелә;

и) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре. Әлеге бүлекчәдә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасының яисә башка түләүнең күләме, яисә мондый пошлина яки түләү күләмен билгеләгән норматив хокукый актның нигезләмәсенә сылтама күрсәтелә;

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ(-лар) турында мәгълүматлар.

л) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре;

м) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне күрсәтү турында гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты;

н) муниципаль хезмәт, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү, шул исәптән электрон формада теркәү срогы һәм тәртибе;

о) муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларны тутыру урыннарына таләпләр, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстта һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән әлеге объектларның инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар йөри алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр;

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән аралашу саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге яисә мөмкин булмавы, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча җирле үзидарәнең башкарма-күрсәтмә органының дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәтләрне 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләрендә алу юлы беләнт теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип) алу мөмкинлеге;

Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә торган очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр.

Әлеге бүлекчәдә электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре күрсәтелә, шул исәптән «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы" республика дәүләт мәгълүмат системасын кулланып:

билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат бирү һәм муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү;

хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны һәм башка документларны тапшыру һәм әлеге гаризаны һәм документларны кабул итү;

хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның үтәлеше хакында мәгълүмат алу;

җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар белән хезмәттәшлеге;

федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләр.

Шулай ук әлеге бүлекчәдә муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләрен билгеләгәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә кулланып була торган электрон имза төрләре күрсәтелә, шул исәптән мөрәҗәгать итүче физик затның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә куллану рөхсәт ителә торган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 нче номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә

кулланыла торган электрон имза төрләре турында» карары белән расланган электрон имза төрләрен билгеләү кагыйдәләре нигезендә гади электрон имза куллану хокукын исәпкә алып, электрон имза төрләре күрсәтелә.

2.5. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составына, эзлеклелегенә һәм башкару срокларына, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләргә, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләренә, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә башкару үзенчәлекләренә кагылышлы бүлекләр административ процедураларның тиешле санына, ягъни муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган, соңгы нәтиҗәгә ия булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында бирелә торган административ гамәлләрнең логик яктан аерымланган эзлеклелекләренә туры килә торган бүлекләрдән тора.

Бүлек башында анда булган административ процедураларның (гамәлләрнең) тулы исемлеге күрсәтелә. Әлеге бүлектә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга ведомствоара соратулар әзерләү һәм җибәрүнең административ процедурасы аерым тасвирлана.

Административ процедураларның (гамәлләрнең) составына, эзлеклелегенә һәм башкару срокларына, аларны үтәү тәртибенә, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләренә кагылышлы бүлектә муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә административ процедуралар (гамәлләр) исемлеге аерым күрсәтелә.

Административ процедураларның (гамәлләрнең) составына, эзлеклелегенә һәм башкарылу срокларына, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләргә, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләренә кагылышлы бүлек үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

Федераль законның 10 статьясы нигезләмәләренә яраклаштырып, административ процедураларны (гамәлләр) электрон формада, шул исәптән "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы" дәүләт мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашыру тәртибе;

муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү тәртибе;

мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү тәртибе, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләренә кагылышлы бүлектә шулай ук муниципаль хезмәтне тулы күләмдә күрсәткәндә һәм муниципаль хезмәтне комплексны сорату юлы белән күрсәткәндә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге тарафыннан башкарыла торган административ процедураларның (гамәлләрнең) тасвирламасы, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрнең һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе булырга мөмкин.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләренә кагылышлы бүлектә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре тарафыннан башкарыла торган административ процедураларны (гамәлләрне) Федераль законның 15 статьясындагы 6 өлешенең 3 пунктчасы нигезендә муниципаль хезмәтләр исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәтләргә карата тасвирлау мәҗбүри.

Әлеге бүлектә шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр тарафыннан түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) башкару тәртибе дә тасвирлана:

мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен үтәүнең барышы, муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле башка мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирү, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең

күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультация бирү;

мөрәҗәгать итүчеләрнең муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгатен һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларын кабул итү;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге тарафыннан башкарма хакимият органнарына, дәүләт хакимиятенең башка органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү;

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән, җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслаучы язмача документлар бирү, шулай ук документларны, шул исәптән язмача һәм җирле үзидарә органнарының мәгълүмат системаларыннан өземтәләр төзүне дә кертеп;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләр, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә файдаланылган көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасының дөреслеген тикшерү, шулай ук әлеге тикшерүне тәэмин итү максатыннан файдалану һәм (яки) мондый хезмәтне күрсәтү өчен рөхсәт ителә торган һәм Россия Федерациясенең Федераль иминлек хезмәте белән килештереп, муниципаль хезмәт күрсәтүне сораган мөрәҗәгатьләрне кабул итү максатыннан кулланыла торган мәгълүмат системасында мәгълүмат куркынычсызлыгына янаучы куркынычларның моделе нигезендә билгеләнгән, башкарма комитет органы тарафыннан расланган таныклаучы үзәкләрнең чаралар исемлеген билгеләү белән бәйле башка гамәлләр.

2.6. Һәр административ процедураның (гамәлләрнең) тасвирламасы:

а) административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигезләр;

б) административ процедура составына керүче һәр административ гамәлнең эчтәлеге, дәвамлылыгы һәм (яки) аны башкаруның максималь вакыты;

в) административ процедура составына керүче һәр административ гамәлне башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат турында мәгълүматлар. Муниципаль хезмәт күрсәтүне турыдан-туры җайга сала торган норматив хокукый актлар конкрет вазыйфага күрсәтмәне үз эченә ала икән, ул административ регламент текстында күрсәтелә;

г) карарлар кабул итү критерийлары;

д) административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе һәм нәтиҗәне тапшыру тәртибе, ул киләсе административ процедураны башкару өчен нигез белән тәңгәл булырга мөмкин;

е) административ процедураның (гамәлнең) башкарылу нәтиҗәсен теркәү ысулы, шул исәптән электрон формада, ул административ процедураның (гамәлнең) мәҗбүри чагылышы форматына күрсәтмәне үз эченә ала.

2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибенә һәм формаларына кагылышлы бүлек түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

а) җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган административ регламент нигезләмәләрен һәм башка норматив хокукый актларны үтәүгә һәм башкаруга, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тәртибе һәм формалары;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр өчен җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының җаваплылыгы;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүне шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан да тикшереп тору тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне аңлата торган нигезләмәләр.

2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл

кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибенә кагылышлы бүлектә күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүчеләр өчен аларның муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кылынган гамәлләргә (кылынмаган гамәлләргә) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукы турында мәгълүмат.

б) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы;

в) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигезләр;

г) мөрәҗәгать итүченең шикаятен судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә җиткерергә мөмкин булган муниципаль хакимият органнары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары;

д) муниципаль хакимият органнары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар;

е) шикаятьне бирү һәм карап тикшерү тәртибе;

ж) шикаятьне карап тикшерү сроклары;

з) һәр процедурага яки шикаять бирү инстанциясенә карата судка кадәр (судтан тыш) бирелгән шикаять нәтиҗәсе;

и) шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү тәртибе;

к) шикаять буенча кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе;

л) мөрәҗәгать итүченең шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алуга хокукы;

м) шикаятьне бирү һәм карау тәртибе турында мөрәҗәгать итүчеләргә хәбәр итү ысуллары.

## III. Вәкаләтле оешма үткәрә торган бәйсез экспертиза һәм экспертиза үткәрү кагыйдәләре. Административ регламентларны куллануга анализ

3.1. Административ регламентларны эшләү барышында җирле үзидарә органы түбәндәге гамәлләрне башкара:

а) административ регламент проектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән административ регламент проектына бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тудыра, административ регламентлар проектларыннан яисә аларның дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләре яки конфиденциаль характердагы белешмәләре булган аерым нигезләмәләреннән тыш.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә административ регламент проекты белән бергә урнаштырыла:

административ регламент проекты буенча тәкъдимнәр кертү сроклары турында мәгълүмат;

административ регламент проекты буенча тәкъдимнәр тапшырылырга мөмкин булган телефон номерлары, факслар һәм электрон почта адресларын күрсәтеп, тәкъдимнәрне җыю, гомумиләштерү һәм исәбен алып бару өчен җаваплы белгечләр исемлеге;

б) бәйсез экспертиза үткәрү кысаларында кызыксынган оешмалардан һәм гражданнардан кергән тәкъдимнәрне карап тикшерә. Тәкъдимнәр административ регламент проекты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә басылып чыкканнан соң 15 көн дәвамында кабул ителә;

в) кызыксынган оешмалардан һәм гражданнардан кергән нигезле бәяләмәләрне исәпкә алып, административ регламент проектын эшләп бетерүне гамәлгә ашыра. Бәйсез экспертиза бәяләмәсенең булмавы әлеге бүлекнең 3.2 пунктында күрсәтелгән экспертизаны үткәрү һәм алга таба административ регламентны раслау өчен каршылык булып тормый.

г) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестры»

дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2010 елның 10 сентябрендәге 729 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль хезмәт турында һәм аның нигезендә эшләнә торган административ регламент турында белешмәләрне, җирле үзидарә органын билгели (үзгәртә) торган норматив хокукый актлар үз көченә кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасын алып бару буенча вәкаләтле органга җибәрә.

3.2. Җирле үзидарәнең административ регламентны раслау өчен җаваплы органы административ регламент проекты, элек чыгарылган административ регламентка үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проекты яки административ регламентны гамәлдән чыккан дип тану турында норматив хокукый акт проекты белән бергә, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча фараз ителгән төп яхшыртулар, бәйсез экспертиза рекомендацияләрен исәпкә алу турында мәгълүмат китерелә торган аңлатма язуын административ регламентны раслау өчен әзерли һәм экспертизага тапшыра.

Административ регламент проектының, элек чыгарылган административ регламентка үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проектының аңа Федераль закон һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлар тарафыннан куелган таләпләргә җавап бирүен, әлеге Тәртип буенча аңа куелган таләпләргә җавап бирүен бәяләү, шулай ук административ регламент проектында бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алуны бәяләү вәкаләтле органның экспертиза ясау предметы булып тора, шул исәптән:

а) административ регламент проектының структурасының һәм эчтәлегенең, шулай ук элек чыгарылган административ регламентка үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проектының, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү стандартының Федераль закон һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлар тарафыннан аларга куела торган таләпләргә туры килүе;

б) административ регламент проектында, элек чыгарылган административ регламентка үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проектында муниципаль хезмәт күрсәтүнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртибе һәм шартлары тасвирламасының тулылыгы;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен оптимальләштерү, шул исәптән:

административ процедураларны (гамәлләрне) тәртипкә салу;

артык административ процедураларны (гамәлләрне) бетерү;

муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында муниципаль хезмәт күрсәтү срогын, шулай ук аерым административ процедураларны (гамәлләрне) башкару срокларын кыскарту;

муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү;

ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алу;

Административ процедураларны (гамәлләрне) күпфункцияле үзәктә башкару үзенчәлекләре.

Административ регламент проектына экспертиза вәкаләтле органга кергән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән ун көнлек срокта башкарыла.

3.3. Административ регламентны раслау өчен җаваплы җирле үзидарә органы вәкаләтле оешма бәяләмәсендә булган искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алуны тәэмин итә. Административ регламент проектының вәкаләтле оешмага бәяләмәгә кабат җибәрү таләп ителми.

3.4. Административ регламентларны куллану практикасын анализлау җирле үзидарә органнары, башка оешмалар тарафыннан түбәндәгеләрне билгеләү максатыннан үткәрелә:

а) административ регламентны башкаруның муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатына һәм һәркем файдалана алырлык булуына туры килүе. Моның белән бергә җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары белән муниципаль хезмәттән файдаланучыларның үзара хезмәттәшлегенең характерын, тиешле муниципаль хезмәтнең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын (бирү вакыты, кабул итүне көтү шартлары, муниципаль хезмәт турында мәгълүмат бирү тәртибе һ.б.) бәяләү билгеләнергә тиеш;

б) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуның нигезле булуы;

в) административ процедураларның оптимальлегенә карата таләпләрне үтәү. Шул ук вакытта артык административ гамәлләр булмау, административ процедураларны һәм административ гамәлләрне башкару срокларын киметү мөмкинлеге билгеләнергә тиеш;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы җаваплы вазыйфаи затларның вазыйфаи регламентларының административ гамәлләр, һөнәри белемнәр һәм күнекмәләрне тасвирлау өлешендә административ регламентка туры килү-килмәве;

д) административ регламентның үтәлешен ресурслар белән тәэмин итү;

е) аңа үзгәрешләр кертү зарурлыгы.

3.5. Административ регламентны куллану практикасын анализлау нәтиҗәләре «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырыла.

Арча муниципаль районы
Урта Курса авыл җирлегендә
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын
эшләү һәм раслау Тәртибенә
кушымта

Типлаштырылган форма

___________________________________
(муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме)
__________________________________

______________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта),
__________________________________

__________________________________
( гражданның шәхси иминият номеры-

__________________________________
СНИЛСы (физик затлар өчен)

__________________________________
(гариза бирүченең почта адресы
__________________________________
(адреслары) электрон почта адресы-
гариза бирүче теләге буенча)
__________________________________
(телефон номеры (номерлары)

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать

_________________________________________________________________
(муниципаль хезмәт атамасы күрсәтелгән гариза тексты)
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________

Кушымталар:
1. ______________________________________________________________;
2.______________________________________________________________;
3.______________________________________________________________.

Муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан, алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан карарлар кабул ителүне исәпкә алып, шул исәптән автоматлаштырылган тәртиптә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системага салу, туплау, саклау, тәгаенләү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхессезләндерү, ябу, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка гамәлләр) үземнең ризалыгымны, шулай ук миңа вәкаләтләр биргән затның ризалыгын раслыйм.
«__» ________ 20__ ел_________________________ ___________________________
(физик зат /юридик зат вәкиленең имзасы) (Ф. и. а. и.)